# 1 Сентябрь – Белем бәйрәме!

**Сентябрь**

**Сентябрь килеп җитте,**
**Кошлар да очып китте.**
**Чәчәкләр башын иде,**
**Үләннәр кибеп бетте.**

**Сентябрь белән бергә,**
**Укулар да башланды.**
**Җәй буена ял иткән,**
**Мәктәпләр каршы алды.**

**Гасимова Язилә, 4г.**



**Көз турында мәкальләр:**

1. Көзге көн арткы акыл, язгы көн арт
2. Көзге көннән язгы төн яхшы.
3. Көзге юлга кием ал, язгы юлга азы

**Гимадиев Ислам, 4г.**




## 1 сентябрь – Белем бәйрәме

Быелгы Белем бәйрәме аеруча күңелле үтте. Көн бик матур, кояшлы иде. Бәйрәм саф һавада, мәктәп ишегалдында булды. Барлык балалар, пөхтә итеп киенеп, кулларына чәчәк бәйләмнәре тотып, шат күңел белән мәктәп бусагасын атлап керделәр.

Бәйрәмне карарга әти-әниләребез, әбиләребез дә килгән иде. Алар, бик шатланып, безнең чыгышыбызны карадылар.

Тәүге тапкыр мәктәпкә килүче нәни дусларыбызны, беренче кыңгырау шылтыравы белән дәрескә озаттык. Аларга без серле белем ачкычын тапшырдык. Беренчеләр бик шат иде!

Менә шулай күтәренке рухта, изге максатлар, хыяллар белән яңа уку елын башлап җибәрдек. Хәерле сәгатьтә, дустым!

**Закиров Айнур, 4г.**



fotolia
#55692493